**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2021 Балык Бистәсе штп. № 268пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "2021елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында" 2021 елның 22 гыйнварындагы №14пи карарына үзгәрешләр кертү хакында

Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру өчен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге №273-ФЗ Федераль законның 79 статьясы, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "2021елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында" 2021 елның 22 гыйнварындагы, №14пи карарының 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәрешләр кертергә

"- 2021 елның 1 декабреннән районның гомуми белем бирү оешмаларының сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән инвалид балалар) 5-11 сыйныф укучылары өчен, әлеге карарга кушымта нигезендә, түләүсез кайнар аш (иртәнге аш) оештырырга;

- район гомуми белем бирү оешмаларының индивидуаль укуга күчерелгән сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән инвалид балалар) 5-11 сыйныф укучыларын коры паек белән тәэмин итәргә».

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарда күрсәтелгән максатларга җирле бюджетның бюджет ассигнованиеләре хисабына муниципаль гомуми белем бирү оешмалары өчен финанс чаралары бүлеп бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 14декабрендәге карарына кушымта

**2021-2022 уку елына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныфларында укучы инвалид балалар һәм сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар саны**

| № п/п | гомуми белем бирү оешмалары | Инвалид балалар (кеше)<br>Барлыгы / индивидуаль укуга күчерелгәннәре | Сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән (кеше) |
|---|---|---|---|
| 1 | «1 нче Балык Бистәсе гимназиясе» МБМУ | **6/0** | **0** |
| 2 | “2 нче Балык Бистәсе урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **9/5** | **10** |
| 3 | «Балыклы Чүкәй урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **1/1** | **0** |
| 4 | “Биектау урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **0** |
| 5 | “Олы Елга урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **2/0** | **1** |
| 6 | “Зур Мәшләк урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **1** |
| 7 | “Югары Тегермәнлек урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **2/1** | **1** |
| 8 | “Күгәрчен урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **2/0** | **0** |
| 9 | “Котлы Бөкәш урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **6/2** | **0** |
| 10 | “Масловка урта белем бирү мәктәбе” | **2/2** | **0** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | МБМУ | | |
| 11 | “Яңа Арыш урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **1/1** | **0** |
| 12 | “Шомбыт урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **1/0** | **1** |
| 13 | “Корноухово урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **0** |
| 14 | “Күки төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **0** |
| 15 | “Түбән Тегермәнлек төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | **1/0** | **0** |
| 16 | “Трой Урай төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **0** |
| 17 | “Урахча төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | **2/2** | **0** |
| 18 | “Шомырбаш төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **0** |
| 19 | “Юлсубино төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **0** |
| 20 | “Ямаш төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | **0/0** | **0** |
| | БАРЛЫГЫ | **35/14(и/о)** | **14** |